ТАТАРСТАН  РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕНЕҢ
«АЕРЫМ ФӘННӘР ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН 45 НЧЕ
УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ  ГОМУМИ БЕЛЕМ  БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ

# *Татар теле һәм татар әдәбияты дәресләрендә картина буенча сочинение язу*

Г.Р.Кәримова  1 нче квалификацион
категорияле татар теле һәм
әдәбияты укытучысы

Яр Чаллы
2018

**Эчтәлек**

**I. Кереш.**

**II. Төп өлеш.**

1. Картина - кеше фикерен график ысул белән чагылдыру чарасы.
2. Рәсем сәнгатенең жанрлары.
3. Әзерлек күнегүләре.
4. План төзү.
5. “Истәлек язуы”.

**III. Йомгаклау.**

## I. Кереш

Сочинение язу кечкенә генә булса да, фәнни эш башкару белән бер. Сочинениедә укучы әдәби әсәрне, тәнкыйди материалны үзләштерү дәрәҗәсен һәм аны анализлау сәләтен, грамоталылыгын, тел чараларыннан файдалана белүен күрсәтә.Үзләренең жанр төрлелеге ягыннан сочинениеләрне берничәгә бүлеп карарга мөмкин. Әкият язу, фантастик хикәя иҗат итү, картина буенча эш, караган спектакль һәм кинофильм турында фикереңне язу, үз тормышыңнан берәр эпизодны сөйләү, тәрҗемәи хәлең, яраткан йорт хайваннарың, дустыңның характерлы сыйфатларын тасвирлау, ел фасыллары турындагы язма эшләр укучыларга кече сыйныфлардан ук тәкъдим ителә. Бу эшләр укучыда мөстәкыйльлек тәрбиялиләр, сөйләм һәм язма тел күнекмәләрен булдырырга ярдәм итәләр, һәм, ниһаять, укучыны югары сыйныфларда биреләчәк язма имтиханнарга хәзерлиләр. Ә инде югары сыйныфларда имтиханнар өчен сочинение темалары үзләренең катлаулы булуы, әдәби материалга нигезләнүе, әдәби тел чараларының байлыгы белән аерылып тора. Тәкъдим ителгән темалар укучының мөстәкыйль фикер йөртүен, нәтиҗәләр ясый белүен, фикерен эзлекле һәм төгәл бирүгә ирешүен таләп итә.

## II. Төп өлеш.

Әдәбият дәресләрен сәнгать әсәрләреннән (рәсем, музыка һәм сынлы сәнгать) башка укучыларның хис-тойгыларына тәэсир итәрдәй итеп үткәрү мөмкин түгеллеге һәр укытучыга бәхәссез дә аңлашыла. Тәҗрибәдә күренгәнчә, мәктәпләрдә картина өстендә эшләүнең төрле алымнары бар. Берәүләр билгеле бер картинаны элеп куялар да, беркадәр әңгәмә үткәргәч, картина буенча сочинение язарга кушалар, икенчеләр теге яисә бу картинаны сөйләм үстерү өчен файдаланалар. Кыскасы, картина өстендә эшләү, ягъни тел-әдәбият дәресләрендә сәнгатьнең башка төрләреннән файдалану яңалык түгел. Шуңа күрә әдәбият укыту программасында һәм дәреслекләрендә Х. Якупов, Л. Фәттахов, И. Шишкин, И. Левитан,

А. Пластов һәм башка рәссамнарның әсәрләреннән үрнәкләр бирелгән.Ә менә чын-чынлап сәнгать әсәрен аңларга, танып белергә өйрәтердәй, картиналарга карап соклану хисе тәрбияләрдәй эш җитәрлек түгел.

Укытучы картиналар буенча эшләгәндә, дәреслек материаллары белән генә чикләнмичә, өстәмә чыганакларга мөрәҗәгать итә ала. Дәреслектән тыш рәссамның башка әсәрләреннән булган репродукцияләре белән дә таныштыра ала. Шәһәр шартларында һәм шәһәргә якын мәктәпләрдә эшләүче укытучылар төрле музейларга экскурсия оештыра алалар. Кыскасы, бу эш укытучының тырышлыгына һәм иҗади якын килүенә бәйле.

Картиналардан файдаланып сочинениеләр язу укучыларның картиналарны яхшы аңлавын һәм рәссамның әйтергә теләгән фикерен «укый» алуларына бәйле. Моның өчен алар һәр детальне бик игътибар белән карап, сәнгать әсәренең гомуми эчтәлегендә аның тоткан урынын бәяли белергә тиешләр.

Укучылар, әлбәттә, рәсем сәнгатенең телен, картиналарның композициясен, төсләр сайланышын, ритмын (ул картинадагы предметларның хәрәкәтен, тынлыкны яки аның артык шау-шулы хәрәкәтен күрсәтү өчен хезмәт итә) да игътибарсыз калдырмаска тиешләр.Билгеле, картина буенча укучыларны сочинениегә әзерләү шулай ук зарури. Тиешенчә әзерлек булмый торып, укучылар без тәкъдим иткән картиналарның эчтәлеген ача алмаячаклар.Картиналарның эчтәлеген «укый алу» өчен укучы аның авторы, бу әсәрнең язылу тарихы белән дә таныш булырга тиеш.Шуның белән бергә укытучы тарафыннан тәкъдим ителгән сораулар һәм биремнәр картиналарның эчтәлеген ачардай һәм укучының игътибарын аны аңларга юнәлтердәй булырга тиешләр.

Картина - кеше фикерен график ысул белән чагылдыру чарасы. Мәктәптә картина-рәсем белән эшләүнең төп максаты-андагы вакыйгаларны йөрәк аша үткәреп, күңел күзе белән карый, аңлый белергә өйрәтү.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, картинаны күзәтүгә берничә минут вакыт бирелә. Укытучы исә балаларның игътибарын сораулар, аңлатучылар белән бүләргә тиеш түгел. Яхшылып карап бетергәннәренә ышанганнан соң гына дәресне дәвам итәргә мөмкин

Беренче этапта:

1.Жанрын билгеләргә

Рәсем сәнгатенең жанрлары: портрет, пейзаж, натюрморт, көнкүреш жанры, тарихи жанр, әкияти жанр һ.б

Портрет - Әдәби әсәрдә кешенең тышкы кыяфәтен (йөз, тән төзелеше, кием, үз-үзен тотышы, эш-гамәлләр, фикер-хисләр, сөйләм) тасвирлау.

1. Портрет-сурәтләү – үзе күргәнчә детальләп күрсәтеп бару.
2. Портрет-чагыштыру – башка персонажлар, билгеле кешеләр, җанлы һәм җансыз күренешләр, әйберләр белән чагыштыру.
3. Портрет-тойгы – герой кыяфәте тудырган хис-тойгыны сурәтләү.
4. Психологик портрет – тышкы кыяфәт аркылы эчке халәтне бирү.

Пейзаж- Әсәрдә җанлы һәм җансыз табигатьне сурәтләү. Вазифалары:

- вакыйганын урынын, вакытын билгеләү;
- сюжетка катнашу яки аны үзгәртү;
- автор фикерен белдерү;

Натюрморт-ул тормыш-көнкүреш әйберләре, чәчәкләр, җиләк-җимешләр, яшелчәләр һ.б. Ләкин алар үсеп утырган хәлдә түгел, ә өзеп, савытка яки өстәлгә куелган рәвештә сүрәтләнә.

2.Картинада нэрсэ (кем) сурәтләнгән?Беренче тәэсир (впечатление).

3.Картинаның композициясе (алгы, арткы план)

4.Образларны тудыру очен нинд төсләр файдаланылган?

5.Бу картина сездә нинди хисләр уятты?

***Алга таба әзерлек күнегүләре эшләү башлана:***

- Картинаның темасын билгеләгәннән соң ,шушы темага җөмләләр төзү;
- Картинадагы һәр предметның нәрсәне аңлатуын әйтү;
-Картинада ясалган предметларның билгеләрен әйтү ( төс, форма, күләм, размер) сүзтезмәләр төзү, җөмләләр төзү, текст төзү;
-Алгы, арткы, үзәктә, уң, сул якта ясалган предметларны әйтү, сөйләү;
-Картинада ясалган ситуация турында сөйләү;
-Төп герой турында сөйләү.( тышкы кыяфәте: күзләре, куллары, киемнәре; үзен тотышы, торышы (позасы)
-Картинага, геройга карата үз фикерләрен өйтү, шул турыда сөйләү;
-Сурәтләнгән эпизодка хәтле, яки аннан соң булган мизгел, күренеш турында хыялланып сөйләү;
-Интерьер,картинада төс, яктылык. колорит, күләгә нинди урын тота?

1.Колорит-картинада яшел,зәңгәр төсләр өстенлек алса,бу салкын төсләр, ә сары, кызыл төсләр өстенлек алса, бу җылы төсләр була.

2.Яктылык-картинада бу кояш нурлары төшкән урыннар.Сочинениедә картина буенча таралган, нурлар чәчеп тора дип кулланырга була

3.Күләгә-картинада яктылык төшмәгән караңгы урыннар.

-Рәссам үзенең геройларына нинди мөнәсәбәттә?Рәссам нәрсә әйтергә тели?
-План төзү.

Картина белән эшләгәндә, план төзү мөһим. Ул уй-фикерләрне тәтипкә сала, әйтер сүзеңне кыска һәм ачык итеп формалаштырырга ярдәм итә. План иҗади эшләргә, сөйләмне эзлекле итеп төзергә ярдәм итә. Башта үрнәк план күрсәтелә. Аның белән танышкач, тактага күмәк төзелгән план языла. Берничә укучы план буенча сөйли. Җаваплар тулыландырыла, өстәмәләр кертелә.

Сочинениеләрнең анализыннан күренгәнчә, укучыларның сүз байлыгы бик чикле. Шуңа күрә сочинение язарга өйрәнгәндә укучыларның сүз байлыгын үстерү юнәлешендә актив эш алып барырга кирәк.Тел байлыгы сай булу (сөйләм ялгышлары турында сүз бара) укучыларның гомуми һәм махсус әзерлеге түбән булуны күрсәтә. Шуңа күрә, нинди материалга

нигезләнеп сочинение язылуга карамастан, бу теманы ачуда файдаланырдай сүзләр группасы бирелергә тиеш.

Балалар картина буенча әңгәмәдә актив катнашырга тиеш. Әңгәмә эчтәлекле булсын өчен, сорауларны дөрес, аңлаешлы итеп бирергә кирәк. Алар билгеле бер эзлеклелектә, берсен-берсе тулыландырып барсын, баланың игътибарын читкә юнәлтмәсен. Әлеге сораулар хикәя төзү өчен план хезмәтен үтәсен.

Картина буенча эш сочинение язу белән тәгълләнә. Укучылар дәрестә анализланган текстны дәфтәргә язалар. Башкача да эшләргә мөмкин. Башта картина буенча күмәк эш алып барыла. Һәр укучы иҗади хикәяләүне мөстәкыйль башкара һәм яза. Өченче варианты да бар: кызыклы эчтәлеге аңлаешлы картиналар буенча эшне тулысынча мөстәкыль рәвештә эшләтергә була. Бу очракта укытучы ярдәме булмый, телдән анализ да үткәрелми, һәр укучы иҗади эшли. Монысы күпмедер тәҗрибә туплаганнан соң гына башкарыла.

Алдында түбәндәге “Истәлек язуы” булса, укучы эзлеклелеккә, төгәллеккә өйрәнә.

1. Теманы билгелә.
2. Үз-үзеңә теманы ачуда ярдәм итүче сораулар куй.
3. Шул сорауларга нигезләнеп, сочинениенең планын төзе.
4. План буенча сөйләп кара.
5. Сочинениене каралamaга яз.
6. Язманы җентекләп тикшер.

Картина буенча сочинение язганда иң мөһиме: үз мөнәсәбәтеңне ачык итеп,эмоциональ итеп җиткерү. Күбрәк синонимнар куллану картинаның авторы, рәссам,ясаган,күрсәткән,әйтергә теләгән һ.б.

## III. Йомгаклау.

Дәрестә алынган белемнәр укучының дөньяга карашы формалашуына зур өлеш кертә. Шул җирлектә аның мөстәкыйль фикере

үсә. Билгеле, моның- өчен дәреснең хәзерлекле, эчтәлекле, үтемле булуы шарт. Шулай булгач, әдәбият дәресе югары дәрәҗәдә сәнгатьлелек үрнәге (уку, сөйләү) булып, укучыларның эмоцияләренә тәэсир итәрдәй итеп үткәрелсен, ягъни укучыларның хисен тәрбияләсен.

Җәмгыятьнең барлык өлкәләрендә барган җитди үзгәрешләр уку-укыту системасында да чагылыш тапты, аның өстенлекле юнәлешен билгеләде. Белем һәм тәрбия бирүнең ахыр максаты булып, әхлаклы, киң белемле, тормышка әзер шәхес тәрбияләү тора. Матур әдәбият исә тулысынча моңа хезмәт итә. Матур сәнгать әсәрләре кешенең эчке дөньясын, рухын формалаштыра, матурлык, гүзәллек тойгыларын үстерә, яшәешкә, яхшылыкның җиңүенә ышаныч тәрбияли. Шуңа да бик күпләр әдәбиятны гомерлек юлдаш итә, сүз сәнгатеннән рухи көч алып яши. Ә язучы әдипләребез исә үзләренең әсәрләре аша без – укучыларны төшенкелеккә бирелмәскә, югалып калмаска, үз кыйблаңнан тайпылмаска өйрәтәләр, матур тормыш корырга илһамландыралар.

## Файдаланылган әдәбият

1.Вәлиева Ф.С. , Саттаров Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы Казан "Раннур" нәшрияты  2000 ел.
2. Хәбибуллина З.Н., Миңнуллина Р.В. Сочинение язарга өйрәнәбез. Казан: "Яңалиф"  2002.
3.Бәширова М.  "Сүз белән сурәт ясау"